МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.11.2019 г.Казань № 1032

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 19 декабрендә 6081 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хокукын билгеләү өчен гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданинның җан башына уртача керем күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 июлендәге 397 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хокукын билгеләү өчен гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданинның җан башына уртача керем күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хокукын билгеләү өчен гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданинның җан башына уртача керем күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 июлендәге 397 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.06.2017 № 349, 07.05.2018 № 348, 18.09.2018 № 885, 02.07.2019 №509 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 15 ноябрендәге 1032 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хокукын билгеләү өчен гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданинның җан башына уртача керем күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 июлендәге 397 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерык аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, курорт җыемын түләүдән азат итү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин кеременең күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, курорт җыемын түләүдән азат итү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин кеременең күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.»;

әлеге боерык белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин кеременең күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

Регламент исемен киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, курорт җыемын түләүдән азат итү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин кеременең күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.»;

1 бүлектә:

1.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, курорт җыемын түләүдән азат итү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин кеременең күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, курорт җыемын түләүдән азат итү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин кеременең күләме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

1.2 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда

кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Үзәк бүлегенең гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчада:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәрне исәпкә алу һәм гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 14, 1257 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Кырым Республикасында, Алтай краенда, Краснодар краенда һәм Ставрополь краенда курорт инфраструктурасын үстерү буенча эксперимент үткәрү турында» 2017 елның 29 июлендәге 214-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 31, 4763 статья);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәрнең төрләре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 512 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2003, № 34, 3374 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш), 1667 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә һәм айлык акчалата түләүләр түләүгә субсидияләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 5, 0156 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге булдыру турында» 2005 елның 20 июнендәге 296 номерлы карары (алга таба – 296 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 25, 0593 статья);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 21 октябрендәге 774 номерлы карары белән расланган Гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәтенә түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибе (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары белән расланган тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, 78, 2625 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Курорт җыемын түләүдән азат итү турында белешмә бирү буенча вәкаләтле орган турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 2404-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2404-р номерлы күрсәтмәсе) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru; 2019, 23 сентябрь).

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «яки шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты)»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, курорт җыемын түләүдән азат итү хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кеременең яки ялгыз яшәүче гражданин керемнең күләме турында белешмә (алга таба – белешмә) бирү | ТР Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары белән расланган тәртипнең 4 нче кушымтасындагы 1 пунктының «а» пунктчасы;<br>ТР Министрлар Кабинетының 2404-р номерлы күрсәтмәсе |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Белешмә бирү (бирүдән баш тарту) | ТР Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары белән расланган тәртипнең 4 нче кушымтасындагы 1 пунктының «а» пунктчасы;<br>ТР Министрлар Кабинетының 2404-р |

| | | |
|---|---|---|
| | | номерлы күрсәтмәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Белешмә бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап 12 эш көне эчендә кабул ителә.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү белешмә бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә | 1. Белешмә бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 1 нче кушымтада китерелде.<br>2. Гаиләнең һәр әгъзасының акчалата һәм натураль формада гариза тапшырылган айдан алдагы өч айлык керемнәре турында документлар, шул исәптән:<br>а) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында»;<br>б) хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы турында; | 44-ФЗ номерлы федераль закон<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 512 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | в) дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация турында;<br>г) эштән куылганда түләнә торган ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы турында;<br>д) барлык дәрәҗә бюджетлардан, дәүләтнең бюджетка карамаган фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр, аңдыйларга түбәндәгеләр керә:<br>пенсияләр, компенсация түләүләре (эшләми торган хезмәткә сәләтле, хезмәткә сәләтсез булган гражданнарны караучы затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм ай саен түләнә торган пенсионерларның матди тәэминаты (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган түләүләрдән гайре);<br>отставкага киткән судьяларны ай саен гомер буе тәэмин итү;<br>һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучыюгары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре;<br>контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр | |

| | | |
|---|---|---|
| | сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе буенча аларның балалары 18 яшенә җиткәнче читләрнең каравына мохтаҗ булса, ирнең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда ай саен түләнә торган пособие;<br>Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эш белән тәэмин итү мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына ай саен түләнә торган компенсация түләүләре;<br>җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре;<br>әлеге пунктчада күрсәтелгән барлык төр социаль түләүләргә өстәмә һәм кушып түләүләр (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән бүтән социаль түләүләр (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);<br>е) хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм 3 яшенә җиткәнче бала карау ялында булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);<br>ж) милекчелек хокукында гаиләнеке (андагы аерым әгъзаларныкы) яисә ялгыз яшәүче гражданинныкы булган мөлкәттән алынган керемнәр, андыйларга түбәндәгеләр керә:<br>күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гараждарны), транспорт һәм бүтән механика чараларын, | |

| | | |
|---|---|---|
| | продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән алынган керемнәр;<br>шәхси ярдәмче хуҗалык уңышын һәм продукциясен (күп еллык утыртмалар, яшелчәчелек продукциясе, продукция һәм демонстрация хайваннары, кошлар, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, бал кортлары, балыклар) сатудан алынган керемнәр;<br>з) гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданинның башка керемнәре турында, аларга түбәндәгеләр керә:<br>хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә азык-төлек тәэминаты;<br>хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнардан эштән киткәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие;<br>Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү;<br>эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең, шул исәптән инвалидлык яисә яше җитүгә бәйле рәвештә пенсиягә чыгу сәбәпле элеккеге, эштән киткән хезмәткәрләренә матди ярдәм;<br>Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турында законнары нигезендә алына торган авторлык бүләкләүләре, | |

| | | |
|---|---|---|
| | шул исәптән мирас итеп алуның авторлык шартнамәләре буенча;<br>эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьянлык (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр;<br>акцияләр буенча керемнәр һәм оешма мөлкәте белән идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;<br>гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар;<br>банк кертемнәре буенча процентлар;<br>мирас итеп алына һәм бүләк ителә торган акча чаралары;<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән ташламалардан һәм социаль гарантияләрдән гаилә әгъзалары алган акчалата эквивалентлар.<br>3. Гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән документ(лар), түбәндәгеләрне раслый торган:<br>аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуын (2 нче кушымта нигезендә тәкъдим ителә торган форма);<br>шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.<br>Эшләми торган граждannар хезмәт кенәгәсе (булган очракта) күчермәсен тапшыра.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп | |

| | | |
|---|---|---|
| | нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан таныклана.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа гариза бирүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:<br>гариза бирүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>опека (попечитель) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) опекада (попечениедә) торучы гражданинны карап тотуга акча алуы турында (җирле үзидарә органнарына); | |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре (түләүләрнең булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан);<br>түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны тәрбия кылучы, эшкә сәләтле эшләүмәүче затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырылучы материаль тәэмин итү буенча түләүләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>Россия Эчке эшләр министрлыгына – пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;<br>хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия Оборона министрлыгы);<br>социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондына);<br>йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында); | |

| | | |
|---|---|---|
| | 1,5 яшенә җиткәнче бала карау ялында булган чорда баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>социаль яклау органнары тарафыннан балага түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарында);<br>әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);<br>җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында).<br>Әлеге документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында | |

| | | |
|---|---|---|
| | билгеләнде.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле | 1. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Гариза бирүченең яшәгән урынына карамаган яисә гариза бирүченең тору урынына карамаган Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе.<br>5. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү.<br>6. Гариза бирүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе. | |
